**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.07.2019 № 590

2019 елга Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында”гы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү Методикасы, 2018 елның 19 декабрендәге 821/пр номерлы“Россия Федерациясе буенча 2019 елның беренче яртыеллыгына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында”гы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының Боерыгы, 2018 елның 19 декабрендәге 822/пр номерлы “2019 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында”гы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының Боерыгы, 2010 елның 25 маендагы “Социаль найм буенча һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак мәйданы нормативлары турында”гы 260 номерлы Карары нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. 2019 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге

һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: 17626,30 сум;

б) ике кешедән торган гаилә өчен: 11216,74 сум гаиләнең һәр әгъзасына;

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен: 9614,35 сум гаиләнең һәр әгъзасына.

1.2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 668250 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 850500 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен -1093500 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен -1458000 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен -1822500 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 2187000 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 2551500 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 2916000 сум.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин